# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«23» 04 2021 ел Яр Чаллы № 1221

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварендәге «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» 128 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын финанслау суммасы артуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 27 мартындагы 519-р номерлы, 2021 елның 20 гыйнварендәге 68-р номерлы күрсәтмәләре нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 гыйнварендәге 128 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына 2021 елга Тукай муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә финанслау күләмен 4435638,00 сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.
2. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләме | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2021-2023 елларда 9 937 638,00 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда – 6 269 638 сум;<br>2022 елда – 1 834 000 сум;<br>2023 елда – 1 834 000 сум. |

| | |
|---|---|
| | Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру чараларының II «Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар» бүлегенә кушымта нигезендә 4159988,00 сум күләмендә финанс средстволары белән «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итү һәм файдалануга тапшыру» пунктын һәм «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу» пунктына 275650,00 сум финанс средстволарын өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның __ апрелендәге ___ номерлы карарына кушымта

**«2021 - 2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын бүлү, еллар буенча (сумнарда) | | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | Барлыгы | | |
| II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар | | | | | | | |
| 1. | Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларын җиһазлау өчен спорт җиһазлары, экипировка һәм инвентарь сатып алу | 275 650 | | | 275 650 | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| 2. | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең универсаль спорт залын оператив идарә итү хокукында беркетелүгә бәйле рәвештә муниципаль заданиенең үтәлешен финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итү һәм файдалануга тапшыру | 4 118 800 | | | 4 118 800 | Республика бюджеты | Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ |
| | | 41 188 | | | 41 188 | Җирле бюджет | |